| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

Якушкино ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10 » ноябрь 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ**:**

1. 2022 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Абрыскино авылы, Гагарин урамы 89 нчы йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Гагарин урамында яшәүче гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 25 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Абрыскино авылы, Гагарин урамы 89 нчы йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Совет урамында яшәүче гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында яшәүчеләрнең гражданнар җыенын үткәрү өчен исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы

ветераннарының тол хатыннары һәм  көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2023 елда һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Абрыскино Авылы торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;

Абрыскино авылында урамнарны яктырту һәм ремонтлау».

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Абрыскино  авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы<br>
Нурлат муниципаль районы<br>
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин